

1992 елның
21 октябреннән
бирле чыга.

# Хезмәттәш авазы

№10 (1198) 3 март, 2016

«ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ» ААҖ

## Фән һәм производство: уртак хезмәт нәтиҗәләре

«Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятенең фәнни-технологик үзәгендә компаниянең баш инженеры И.Шәрифуллин җитәкчелегендә киңәшмә узды.



2 бит

## «Нефтехимик» лаеклы уен күрсәтте

26, 28 февраль көннәрендә «Нефтехимик» КХЛ чемпионатының плей-офф матчлары кысаларында үз бозында «Авангард» (Омск) командасы белән көрәште.

5-6 бит

12+ яшь һәм аннан өлкәнрәк укучылар өчен



## *Кадерле «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыяте хатын-кызлары!*

*Искиткеч бәйрәм – 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан ихлас котлаулар һәм сезнең бала тәрбияләү, үзегез булган һәр җирдә дә уңайлык һәм тәртип булдыру, шул ук вакытта һөнәри эшчәнлегегездә һәм җәмәгать эшләрендә зур уңышларга ирешү буенча осталыгыгыз өчен рәхмәт сүзләре кабул итеп алыгыз!*

*Сез мәхәббәт һәм гармонияне, тынычлык һәм татулыкны гәүдәләндерәсез! Без, ир-атлар, сезнең кабатланмас гүзәллегегез, мөлаемлыгыгыз һәм ихлас сөйкемлегегезгә, һәрвакытта да сылу һәм сокландыргыч була белүегезгә хәйран калабыз, сезнең талантларыгыз, энергиягез һәм эшсөючәнлегегез белән горурланабыз.*

*Әлеге язның беренче бәйрәме алдыннан акционерлык җәмгыятенең барлык ир-егетләре исеменнән сезгә, кадерле хатын-кызлар, саулык-сәламәтлек, бәхет, муллык, иминлек һәм күңел күтәренкелеге телим. Тормышыгыз һәрвакыт яз кебек кояшлы, шатлыклы һәм матур булсын!*

***«Нефтехим» җәмгыяте генераль директоры** **А.БИКМУРЗИН***



*8 Март белән!*

ПРОИЗВОДСТВО

# Экологик яктан да файдалы

**Бутилкаучук заводында автоцистерналарга продукция тутыру буенча автоматлаштырылган җайланма сафка басты.**

БК заводының 1311нче цехы карамагындагы яңа җайланма изопрен-мономер заводында диметилдиоксан җитештерү процессында бүленеп чыгучы ян продукт – флотореагентларны автоцистерналарга тутыру өчен кулланыла. Цехта элегрәк вакытлы тутыру җайланмасыннан файдаланганнар. Ләкин бу өлкәдә кагыйдәләрнең кырысланызы нефтехимиклар алдына экология һәм сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә җавап бирүче заманча тутыру җайланмасын төзү зарурлыгын куя.

Флотореагентларга килгәндә, аның төрле маркалары линолеум, резин-техник эшләнмәләр һәм автомобиль сәнәгате өчен сыеклыклар җитештерүдә киң файдаланыла. Әлеге ян продуктларны ИМ заводыннан үткәргеч торба аша Т-8/1 титуллы складка суыртлалар.

Яңа тутыру җайланмасын узган елның августында өлешчә куллана башлыйлар. Аның начальнигы Ханнан Бирдеголов әйтүенчә, яңа корылманың проектын төзеп, аны тормышка ашыруга керешү, җиһазлар монтажлау эшләре, чагыштырмача, тиз арада башкарылган.

– Тутыру җайланмасы заманча прибор-датчиклар белән җиһазландырылган. Биредә автоцистерналарга тутырыла торган продукция турындагы барлык төгәл мәгълүмат - авырлыгы, күләме, температурасы һәм башкалар - операторлар бүлмәсендәге компьютерларга килә, – ди Х.Бирдеголов.

Аның сүзен дәвам итеп, 1311нче цех аппаратчысы Ләйсән Архиреева түбәндәгеләрне өсти:

– Безнең эш компьютерларга нигезләнгән. Операторлар бүлмәсендә кирәкле масса күрсәткечләрен, автобойлерга күпме продукция тутырырга кирәклеген язып, компьютерга кертәбез. Шуннан соң, кнопкага басуга, ул билгеләнгән күләмдә цистернага ага.



Ләйсән АРХИРЕЕВА

Әйе, продукцияне җитештерү бер мөһим бурыч булса, икенчесе – аны, югалтуларга юл куймыйча, кулланучыларга озату. Сүз уңаеннан: флотореагентларга Россиядә дә, чит илләрдә дә сорау бар. Ә тутыру процессының герметик шартларда алып барылуы, әлбәттә, продукцияне әрәм-шәрәм итүгә чик куя. Шул ук вакытта, яңа тутыру җайланмасын куллануга тапшыру тирәяк мохитне саклау юнәлешендә дә әһәмиятле адым булуын билгеләп үтү зарур. Чөнки яңа җайланманың җиңсәсен автомобиль цистернасына, аның авызы (горловина) нинди диаметрда булуына карамастан, герметик рәвештә тоташтыру мөмкин. Димәк, автоцистернага тутырыла торган продуктның тамчысын да читкә чыгаруга һәм шул рәвешле тирә-як

(Ахыры 2нче биттә)


Реклама хокукында.

ИШЕТМИ КАЛМА!

## Дүрт көн ял

**Мартның беренче атнасында россиялеләрне дүрт көн ял көтә.**

Быел 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне сишәмбегә туры килә. Россия Хөкүмәте карары нигезендә, агымдагы елда якшәмбегә туры килгән 3 гыйнвар ялы 7 мартка (дүшәмбегә) күчерелгән иде. Нәтиҗәдә мартның беренче атнасында 4 көн рәттән – 5 (шимбә), 6 (якшәмбе), 7 (дүшәмбе), 8 март (сишәмбе) көннәрендә ял итәчәкбез. Ә чәршәмбе, 9 март көнне - эшкә.



КИҢӘШМӘ

# Фән һәм производство: уртак хезмәт нәтиҗәләре



И. ШӘРИФУЛЛИН һәм И.БЕЛАНОГОВ

**«Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятенең фәнни-технологик үзәгендә (НТЦ) компаниянең баш инженеры Илфат Шәрифуллин җитәкчелегендә киңәшмә узды.**

*Анда үзәкнең 2015 елгы эшенә йомгак ясалды, 2016 елга планнары игълан ителде.*

*Киңәшмә эшендә компаниянең баш белгечләре, подразделениеләр җитәкчеләре катнашты. Соңыннан НТЦ директоры И.Беланогов массакүләм мәгълумат чаралары хезмәткәрләренең сорауларына җавап бирде. Ә СК заводының баш инженеры И.Мисбахов НТЦ белән хезмәттәшлек итүләре турында сөйләде. Аларның чыгышын, бераз кыскартып, газета укучыларга тәкъдим итәбез.*

### И.Беланогов:

– Безнең фәнни хезмәтләр, тикшеренүләр, тәҗрибә-сәнәгать сынаулары үткәрүләр барысы да «Нефтехимик» акционерлык җәмгыятенең эшенә турыдан-туры бәйләнгән. Киңәшмәдә аеруча актуаль мәсьәләләр буенча җентекле сөйләшү булды. Без ел дәвамында уздырылган тикшеренүләр турында сөйләдек. Аерым алганда, полимерлар – полиэтилен, полипропилен, АБС-пластиклар һәм полистироллар җитештерү буенча зур эш башкарылды. Моннан тыш, нефть химиясе синтезы мәсьәләләре белән шөгыльләндек. Биредә СК, ИМ заводларында, СПС заводының мономерлар производствосында продукция җитештерү мәсьәләләренә тукталып үтәргә мөмкин. Олигомерлар, этилен, этилен окисе заводлары буенча проблемалар булды. Бүгенге очрашу – 2015 елда башкарылган күләмле эшләргә йомгак ясау.

Соңгы вакытта лабораторияләрдә дә, тәҗрибә-сәнәгать цехында да дивинил-стироллы каучукны синтезлау буенча мөһим тикшеренүләр үткәрдек. Резин-техник эшләнмәләргә, аерым алганда, автомобиль покрышкаларына заман таләпләре бик югары. Сүз аларның ныклыгы, таушалуга чыдамлыгы, юеш юлга тоташу дәрәҗәсе һәм башкалар турында бара. Бу параметрларның барысы да әһәмияткә ия, чөнки алар кеше гомеренә һәм тирә-як мохитнең торышына бәйләнгән. Автомобиль покрышкаларындагы ниндидер кимчелек-җитешсезлекләр зур финанс чыгымнарына китерергә мөмкин. Шуңа күрә 2015 елда каучукның әлегә Россиядә җитештерелми торган принципиаль яңа төрләрен эшләп чыгару максатыннан, берничә сынау үткәрдек. Сүз уңаеннан: сынаулар әле дәвам итә һәм йомгаклау стадиясенә якынлаша. Җәй айларында ул эшләрне тәмамлап, 2016 ел ахырында беренче сәнәгать үрнәкләрен алырга планлаштырабыз.

### И.Мисбахов:

– СК заводы – компаниядә иң зуры һәм безнең НТЦ белән бергә алып бара торган эшләр дә күп төрле. Бу бүген заводта җитештерелә торган һәм киләчәктә җитештереләчәк каучукларга да кагыла. Эш, гомумән, барлык юнәлешләрдә дә алып барыла. Без фәнни-технологик үзәктән калышмаска тырышабыз. НТЦ тарафыннан тәкъдим ителгән фикерләрнең файдалы һәм нәтиҗәле булуларын билгеләп үтәргә кирәк. Һәм без ул фикерләрне мөмкин булган кадәр тиз арада тормышка ашырырга тырышабыз. Әгәр дә тәҗрибә-сәнәгать сынаулары уңай нәтиҗә бирсә, аларны шунда ук производствога кертәбез. Дөрес, бу эш кулланучылар белән килешеп эшләнә, чөнки алар бездә җитештерелә торган каучукларның сыйфаты яхшыруын белеп торырга тиеш. Ә заводның мономерлар өлешендә эш күп әле. Биредә, минем фикеремчә, НТЦ галимнәре өчен дә, аеруча продукциянең үзкыйммәтен киметү, аның конкуренциягә чыдамлыгын үстерү өлкәсендә, эш фронты гаять киң.

НТЦга килгәндә, соңгы елларда аның коллективы шактый яңаруын билгеләп үтәсе килә. Яшь хезмәткәрләрнең күп булуына да карамастан, НТЦның күпьеллык тәҗрибәсен саклап кала алуы куандыра. Бу – әһәмиятле факт. Мин әлеге яшь коллективның элеккеге традицияләрне дәвам итүен, базар, икътисад һәм, әлбәттә, безнең завод таләпләрен дә исәпкә алып, заман белән бергә атлавын телим.



И. МИСБАХОВ

Киңәшмәгә йомгак ясап, «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – баш иженер **И.Шәрифуллин** башкарылган эшләре өчен НТЦ хезмәткәрләренә рәхмәт белдерде һәм алар алдында торган бурычларга тукталып узды:

– 2016 ел альфа-олефиннар производствосын куллануга тапшыру белән истәлекле булачак. Безгә алга таба цирконийлы катализатор җитештерүне үзләштерергә кирәк, чөнки ул бутилның да, гексенның да, шулай ук полиэтиленның да үзкыйммәтен киметү мөмкинлеге бирәчәк.

2016-2017 елларда тагын бер юнәлеш – изопренны бер стадияле юл белән җитештерү күләмен арттыру. Шуның нәтиҗәсендә шактый күп ян продукт, төрле абсорбентлар планлаштырыла. Бу өлкәдә эшләп, аларны лаеклы файдалану мөмкинлегенә ирешү зарур.

Пластиклар, каучуклар буенча 2016 елда алда торган бурычларга килгәндә, без, тулаем дөнья базарында конкуренциягә каршы тору өчен, продукциянең яңа төрләрен булдырырга тиеш.

Икенче сәнәгать зонасындагы производстволарның эшенә тукталып, гади полиэфирларның яңа маркаларын алу бурычы торуын ассызыклап узасым килә. Шул уңайдан чит илләрдәге җитештерүчеләрнең эшләре белән танышырга, яңа рецептуралар булдырырга, продукциянең яңа маркаларын җитештерүне үзләштерергә тиешбез. Моннан тыш, яңа этилен комплексы төзелү уңаеннан, шуның белән бәйле эшләрне күз уңында тотарга кирәк булачак.

Реклама хокукында.

# Экологик яктан да файдалы



(Ахыры. Башы 1нче биттә)

мохиткә зыян салуга юл куелмый: барлык парлар җыеп алына һәм факел җайланмасында яндырыла. Моннан тыш, яңа корылмада тутыру процессы автоматлаштырылган контроль астында алып барыла. Бу исә, үз чиратында, кирәгеннән артык продукция тутыру, цистерналарны таштыру очракларына чик куя.

Бүген тутыру җайланмасы тагын да камилләштерелә дип әйтергә мөмкин. Аның икенче модулендә кулланучыларга абсорбентлар озату мөмкинлеген булдыру планлаштырыла. Гомумән алганда, яңа җайланманың ресурсы зур: кирәк булса тутырыла торган продукциянең күләмен тагын да арттырырга мөмкин.

Белешмә өчен: абсорбентлар – «Нефтехим» акционерлык җәмгыяте производстволарында да продукция җитештерү процессында барлыкка килгән ян продуктлар. Кулланучылар аларны, нигездә, мич ягулыгы сыйфатында файдалану өчен сатып алалар.

*Рәхим ЗАКИРОВ*

Реклама хокукында.

## Экологик белешмә

**22.02.16-29.02.16**

### Эчә торган су

«Су чистарту станциясе-НКНХ» җәмгыятендә әзерләнгән һәм шәһәргә эчү өчен бирелә торган суның сыйфаты санитар норма таләпләренә җавап бирде. 29 февральдә Кама елгасында суның биеклеге 51,3 метр (Балтика биеклек системасы буенча) тәшкил итте.

### Агымсулар

Биологик чистарту корылмаларында чистартылганнан соң, Кама елгасына агызыла торган агымсулар составында, узган атна күрсәткечләре белән чагыштырганда, тимер, нитритлар һәм хлоридлар күләме артты, сульфатлар һәм цинк – кимеде, ә бакыр күләме узган атнаның уртача күрсәткечләре дәрәҗәсендә булды. Агымсулар составында ванадий, титан, ацетофенон, метанол, фенол табылмады.

### Һава

Узган атнада торак пунктларда һава составын тикшерү нәтиҗәләре:

**Прости авылы:** 22 февральдә һава составында аммиак күләме 0,02 мг/м$^3$ (норма-0,2 мг/м$^3$) тәшкил итте.

Формальдегид, толуол, бензол, этилбензол, ацетальдегид, ацетофенон, хлорметан, азот оксиды, азот диоксиды, стирол, дивинил, этилен оксиды, пропилен оксиды, фенол, углерод оксиды, диметилбензол күләме тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды.

**Зур Афанас авылы:** 23 февральдә һава составында чикле углеводородлар күләме 0,4 мг/м$^3$ (50,0 мг/м$^3$) тәшкил итте.

Стирол, толуол, этилбензол, хлорметан, бензол, күкертле водород күләме тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды.

**Вахитов проспекты** (максималь һәм минималь күрсәткечләр)

– аммиак күләме 26 февральдә 0,05 мг/м$^3$ (0,20 мг/м$^3$) тәшкил итте, 27 февральдә тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды;

– азот диоксиды күләме 26 февральдә 0,04 мг/м$^3$ (0,2 мг/м$^3$) тәшкил итте, 25 февральдә тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды;

– бензол күләме 23 февральдә 0,009 мг/м$^3$ (0,3 мг/м$^3$) тәшкил итте, 25 февральдә тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды;

– чикле углеводородлар күләме 26 февральдә, 07.00 сәгатьтә – 1,6 мг/м$^3$ (50,0 мг/м$^3$), 26 февральдә 13.00 сәгатьтә 1,3 мг/м$^3$ тәшкил итте;

– толуол күләме 23 февральдә 0,546 мг/м$^3$ (0,6 мг/м$^3$) тәшкил итте, 26-27 февраль көннәрендә тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды.

Һава составында стирол, этилбензол, формальдегид, күкерт диоксиды, фенол, ацетальдегид, хлорметан, дивинил, этилен оксиды, пропилен оксиды, ацетофенон, диметилдиоксан, дициклопентадиен күләме тикшерү методикасы сизгерлегеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булды.

### Калдыклар

Узган атнада «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятендә калдыклар белән эшләү буенча нормадан тайпылу очраклары теркәлмәде.

**Тирә-як мохитне саклау бүлеге.**



СИНЕҢ КЕШЕЛӘРЕҢ, «НЕФТЕХИМ»!

# Мөлаем, уңган һәм тырышлар

**«Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятендә хезмәт куючы хатын-кызлар арасында нинди генә һөнәр ияләре юк. Һәм, әлбәттә, аларның һәрберсе мөлаем, уңган, тырыш, кыскача әйткәндә, мактау сүзләренә лаек.**

**8 март – Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан, күптән нигез салынган матур традиция буенча, компаниянең генераль директоры акционерлык җәмгыятендә эшләүче һәм аеруча яхшы күрсәткечләргә ирешкән гүзәл затларны очрашуга чакырып, бәйрәм белән котлый. Быел, әлеге чара алдыннан, тантанага чакыру алган хатын-кызларның берсе – бутилкаучук заводының 1308нче цех хезмәткәре Вәсилә Харисова белән очрашып, әңгәмә кордык.**



*Вәсилә ХАРИСОВА һәм Флёра ГАЗИЗУЛЛИНА*

Аның хезмәт вазыйфасы – пресслаучы. Ә «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятендә эшләвенең тарихына килгәндә, Вәсиләгә биргә килеп эшкә урнашырга абыйсы киңәш биргән. Ул үзе узган гасырның 80нче елларында ук 62нче һөнәр училищесын тәмамлаган, сеңлесе шәһәргә килгәндә аның нефтехимик буларак стажы биш елдан артып киткән була. Шулай итеп, туганының киңәшеннән файдаланып, Вәсилә дә нефтехимиклар коллективын тулыландыра. Һәм, әйтергә кирәк, аның әлеге каучук бүлеп чыгару һәм киптерү цехында эшли башлавына гына да инде 20 елдан артык вакыт үткән. Элегрәк – «Андерсон», хәзер исә «Велдинг» каучук бүлеп чыгару агрегатында эшли ул. Соңгысын эшләтеп җибәрү вакыты да алар сменасына туры килгән.

– Безнең эш читтән карап торганда бик җайлы күренсә дә, аның үз авырлыклары да, җиңел яклары да бар. Без конвейердан узучы каучук брикетларын күзәтеп торабыз, контрольдә тотабыз. Продукциянең сыйфатына таләпләр югары, аның составында бернинди дә кушылмалар булмаска тиеш. Шуңа күрә пресслаучы машинаның эшен даими күз уңында тотарга кирәк, - дип үзенә йөкләнгән бурычлар белән таныштырды Вәсилә ханым.

Түбән Кама районының Түбән Уратма авылында туып үскән, шунда мәктәп тәмамлаган һәм кечкенәдән йорт-хуҗалык эшләрендә катнашып үскән кызны химкомбинаттагы яңа һөнәре дә, физик хезмәт тә куркытмый. Гомумән, беренче көннәрдә тау кадәр олы җиһаз-агрегатлар янына барырга да шикләнеп торган кыз – бүген үз эшен барлык нечкәлекләренә кадәр өйрәнгән, зур тәҗрибә туплаган һөнәр иясе.

– Бөтен дөньяга танылган шундый предприятиедә эшләү – безнең өчен дә горурлык. Ә эшче һөнәренә килгәндә, ул һәрвакытта да дәрәҗәле булды һәм булыр дип саныйм, – ди Вәсилә Харисова һәм үзе турында түгел, күбрәк бергә эшләүче хезмәттәшләре, аларның тырышып, үзләренә тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкарулары турында сөйләргә тырыша.

– Остазым, Әнисә Мөбәракшинага рәхмәтем зур. Озак еллар аның белән бергә эшләдек, ул үз эшен яратып, күңел биреп башкара иде. Мине дә шуңа өйрәтте, – дип дәвам итә Вәсилә ханым.

Алар хезмәт күрсәтә торган «Велдинг» агрегаты сәгатенә 8 тонна каучук бүлеп чыгара. Берсенең авырлыгы 30 килограмм тирәсе булуын исәпкә алганда, пресслаучыларга бер сменада ничә каучук брикетын тикшерергә туры килүен санап чыгаруы авыр түгел. Шуңа өстәп, Вәсилә Харисова бүген үзе, остаз буларак, цехка килүче яшьләрне эшкә өйрәтә, тәҗрибәсе белән уртаклаша.


Цех җитәкчелегеннән, хезмәттәшләреннән дә Вәсилә ханым турында бик күп яхшы сүзләр ишетек.

– Без Вәсилә Харисова белән күптән бергә эшлибез, гаиләләребез белән дус яшибез, йөрешәбез. Ул эштә дә, гаиләсендә дә үрнәк булырлык хатын-кыз. Алар ире Зөфәр белән бергә ике бала тәрбияләп үстерделәр, аларга югары белем бирделәр, - ди хезмәттәше турында 1308нче цех пресслаучысы Флёра Газизуллина һәм цехта, җитештерү процессында алар катнашында булып узган истәлекле вакыйгаларга туктала.

Менә шундый, Вәсилә Харисова кебек, дистәләрчә, йөзләрчә тәҗрибәле һөнәр осталары эшли бүген «Нефтехим» җәмгыятендә һәм компания ирешкән уңышларга үзләренең лаеклы өлешләрен кертәләр.

ХОККЕЙ

# «Нефтехимик» лаеклы уен күрсәтте



**26, 28 февраль көннәрендә «Нефтехимик» КХЛ чемпионатының плей-офф матчлары кысаларында үз бозында «Авангард» (Омск) командасы белән көрәште.**

Ә аңа кадәр көндәшләр Омск шәһәрендә ике матч үткәрүе, аларның беренчесендә «Нефтехимик»ның 1:2 исәбе белән оттыруы турында хәбәр иткән идек инде. 24 февральдә узган икенче уенда да, кызганычка каршы, боз хуҗалары көчлерәк булды. Гомумән, икенче период уртасына кадәр «Авангард» нефтехимиклар капкасына 3 җавапсыз алка керткән иде – 3:0. Ләкин куначлар, период тәмамланганчы бер җавап алкасы кертеп, ә икенче период башында исәп аермасын тагын да кыскартып (3:2), «Нефтехимик»ның җанатарлары күңелендә өмет чаткысы уятты. Әйе, нефтехимикларның исәпне тигезләргә мөмкинлекләре дә булды, ләкин боз хуҗалары моңа юл куймады. Ә өченче периодның соңгы минутларында, безнекеләр капкачыны алтынчы уенчы белән алыштырып, «Авангард» капкасына хәлиткеч һөҗүм оештырган мизгелләрдә, боз хуҗалары аларның бер хатасыннан оста файдаланып, алканы буш капкага кертте – 4:2. Шул рәвешле «Нефтехимик», икенче матчта да оттырды.

– Беренче һәм өченче периодларны команда лаеклы үткәрде, грамоталы, яхшы уен күрсәтте. Ә икенче периодта, исәп 2:0 булгач, уенның тәртибен югалттык, нигәдер йөгерә башладык. «Авангард» белән алай уйнап булмый, – диде «Нефтехимик»ның баш тренеры вазыйфасын башкаручы Евгений Попихин уен тәмамланганнан соң.

26 февральдә «Нефтехимик» плей-офф кысаларында “Авангард” белән үз бозында беренче уенын үткәрде. Матчның беренче периодында боз хуҗалары активрак булса да, алка кертә алмадылар. Аларның активлыгын исә капкага төзәп аткан алкалар саны да раслый: беренче периодта боз хуҗалары – 29, куначлар – 19 алка атты. Шуңа да карамастан, период ахырында «Авангард» исәпне ачып, алга чыкты – 1:0. Ул гына да түгел, икенче периодның икенче минутында ук куначлар тагын бер алка кертеп, әлеге уңышларын ныгытуга да иреште. Дөрес, безнекеләр икенче периодта да актив уйнады, тырышты, көндәшләре капкасына һөҗүмнәрне дә, аларга караганда, күбрәк оештырды, ләкин аларның берсе дә гол белән тәмамланмады. Ә өченче период, гомумән, тулысынча нефтехимикларның өстенлеге белән узды. Алар алкаларны да куначларга караганда 11 тапкыр күбрәк атты (33-3). Шуның нәтиҗәсе буларак, период уртасында Якимов бер алка кертеп, исәп аермасын кыскартуга иреште – 1:2. Әлеге уңыш нефтехимикларга бераз өстәмә көч бирсә дә, «Авангард» оборонага игътибарны тагын да арттырып, аларга исәпне тигезләргә юл куймады. Нәтиҗәдә «Нефтехимик» өченче матчта да оттырды (1:2).

– Уйлавымча, бүген сезонның иң яхшы уенын үткәрдек. Дөрес, алка кертергә мөмкинлекләр күп булса да, аларны тормышка ашыра алмадык. Гомумән, алка кертү – безнең өчен төп проблема. Һәм, әлбәттә, уен барышында бик яхшы атмосфера булдырулары өчен җанатарларга зур рәхмәт, – диде Евгений Попихин уенга йомгак ясап.

28 февральдә «Нефтехим Арена»да көндәшләр кабат очрашты. Ул уенда боз хуҗалары беренче периодның өченче минутында исәпне ачуга һәм период ахырын-

(Ахыры 6нчы биттә)

## Хәбәрләр

**Россия Федерациясендә сөт җитештерү күләме арткан.** 2016 елның гыйнварында авыл хуҗалыгы оешмаларында ул 29,8 мең тоннага яки 2,6 процентка арткан. Тулаем алганда, сөт җитештерү 1,17 млн тоннага җиткән. Сүз уңаеннан: Татарстанда артым 3,8 мең тонна (4,8 процент) тәшкил иткән.

**Россиядә иртә өйләнүне тыя торган закон проекты карала.** Яңалык тәкъдим итүчеләр фикеренчә, иртә өйләнү – бозыклык билгесе. Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген илнең 17 төбәгендә 14 яшьтән өйләнергә рөхсәт ителә. Мәсәлән, Түбән Новгород, Орел, Ростов өлкәләрендә, Кабарда-Балкарда үсмерләр 16 яшь тулганчы ук ЗАГСка бара ала. Җитди сәбәпләр булганда, әлбәттә. Гомумән алганда, балигъ булмаганнар белән гаилә кору шартларын, Гаилә кодексы нигезендә, җирле хакимият билгеләргә тиеш.

**Менделеевскида «Аммоний» җәмгыятенең яңа комплексы тәкъдим ителде.** Анда аммиак, метанол һәм гранулалы карбамид җитештереләчәк. Әлеге комплекс минераль ашламалар җитештерү заводы базасында гамәлгә ашырыла. Аны төзүдә 9 илдән 3,5 мең кеше хезмәт куйган. Фаразланган еллык җитештерү күләме 717 мең тонна аммиак, шулкадәр үк карбамид, 233 мең тонна метанол, 300 мең тонна аммиак селитрасы тәшкил итә. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, Россия елына 1 млрд кубометр табигый газ эшкәртүгә сәләтле заманча комплекска ия булды. Әйтергә кирәк, дөньяда мондый заводлар нибары икәү.

**Татарстанда мелиорация буенча программаларга игътибар арта.** 2015 елда, мисал өчен, 162 гектар мәйданда җиләк-җимеш бакчалары тамчылы сугаруга көйләнгән, яшелчә культуралары өчен өч мең гектардан артык сугарулы җирләр әзерләнгән. Быел мелиорация буенча программаларны тормышка ашыру дәвам итә: 3 мең гектардан артык сугарулы җир төзү һәм реконструкцияләү, 60тан артык буаны һәм гидротехник корылмаларны торгызу, 230 гектардан артык җиләк-җимеш бакчасын тамчылы сугаруга көйләү планлаштырыла.

**Казанда крестьянга һәйкәл ачмакчылар.** Бу хактагы карар Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының XVI съездында кабул ителгән. Әлеге тәкъдим белән Алексеевск районы эшмәкәрләре чыккан. Фикер Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов тарафыннан да хуплау тапкан. Шулай итеп, һәйкәлне Игенчеләр сарае каршына урнаштыру турында килешенгән.

# «Нефтехимик» лаеклы уен күрсәтте

(Ахыры. Башы 5нче биттә)

да тагын бер алка кертеп, исәп аермасын арттыруга да ирешә – 2:0. Ләкин, кызганычка каршы, алар әлеге өстенлекне саклап кала алмады: "Авангард" икенче периодның 15нче минутында – бер, өченче период уртасында икенче җавап алкасын кертеп, исәпне тигезләде – 2:2. Шуннан соң командалар икесе дә оборонага игътибарны арттырып, сакланып, хаталарга юл куймаска тырышып уйнады. Нәтиҗәдә өченче период тигез исәп белән тәмамланды һәм матчның хөкемдары җиңүчене ачыклау өчен, регламент нигезендә, овертайм үткәрелүе турында игълан итте.

Беренче овертайм, икенчесе... Бары тик өченче овертаймның өченче минутында гына кунакларның һөҗүмчесе Паршин уңышка ирешеп, әлеге 102 минуттан артык дәвам иткән матчка нокта куйды һәм «Авангард»ка җиңү бүләк итте. Шулай итеп, "Нефтехимик" киеренке көрәштә 2:3 исәбе белән оттырды һәм Гагарин кубогы өчен көрәштән төшеп калды.



Соңыннан команданың тренерлары уенга йомгак ясады:

**Евгений Корноухов,** «Авангард»ның баш тренеры:

– Серия 4:0 исәбе белән тәмамланса да, ул безнең өчен бик авыр узды. Безгә каршы яхшы команда көрәште, ләкин без аз гына уңышлырак уйнадык.

**Евгений Попихин,** «Нефтехимик»ның баш тренеры вазыйфасын башкаручы:

– Без плей-оффта көч сынашу тәҗрибәсе булган көчле командага каршы уйнадык. Әлеге дүрт уенда көрәшкән егетләргә рәхмәт сүзләре җиткерәм. Без һәр матчта лаеклы чыгыш ясадык, көрәштек, егетләр характер күрсәтте.

*Рәхим ЗАКИРОВ*

*К.Губарев фотолары*

СӘНГАТЬ БӘЙГЕСЕ

**Түбән Каманың 27нче мәктәп укучысы Леонид Храмов «Моң чишмәсе» татар сәнгате төбәк фестиваль-конкурсында катнашып, дипломант исеменә лаек булды.**



## Яр Чаллыдан бүләк белән

Февраль ахырында Яр Чаллыда узган әлеге бәйгедә Татарстан шәһәр һәм районнарыннан 400дән артык сәнгать сөюче катнашты. Конкурсантлар төрле музыкаль инструментларда уйнау, шулай ук җыр, театр, рәсем сәнгате буенча ярышып, сәләт һәм осталыкларын күрсәтте.

Түбән Камадан 27нче мәктәпнең 1нче сыйныф укучысы 7 яшьлек Леонид Храмов (рәсемдә, унда) башкаруындагы «Әссәләмәгәләйкүм» җыры жюри әгъзаларының күңеленә аеруча хуш килә. Нәтиҗәдә ул «Эстрада җыры» номинациясендә өченче дәрәҗәле диплом белән бүләкләнә. Тагын бер түбәнкамалы - 25нче гимназиянең 1нче сыйныф укучысы Дамир Фадеев (рәсемдә) бәйгедә музыкаль инструментта (фортепиано) уйнау буенча осталыгын күрсәтә.

– Улымның әлеге уңышка ирешүендә 68нче балалар бакчасының татар теле тәрбиячесе Гайнуллина Фәния Ниязовнаның өлеше зур, – ди Леонидның әнисе Светлана Храмова һәм Фәния Гайнуллинаның, музыка мәктәбе хезмәткәре Ольга Елагина белән бергә, балаларны әлеге һәм башка чараларда катнаштыру өчен зур тырышлык куюлары турында сөйли.

Светлана Храмова әйтүенчә, Дамир фортепианода татар көйләрен шактый оста башкарса да, жюри әгъзалары бу номинациядә өлкән яшьтәге конкурсантларны гына дипломнар белән билгеләп үтү турында карар кабул итә. Димәк, үсә төшкәч әле Дамир белән Леонидның төрле дәрәҗәдәге татар сәнгате бәйгеләрендә уңышлы чыгыш ясаячакларында шик юк.

НЕФТЕХИМИКЛАР ИҖАТЫ

### Шундый рәхәт миңа

Синең белән шундый рәхәт миңа,
Гел сизмимен вакыт үткәнен.
Онытыла бөтен борчуларым,
Син үзедер минем көткәнем.

Синең белән шундый рәхәт миңа,
Аңлатырга җитми сүзләрем.
Йөзеп йөрим бәхет диңгезендә,
Карап туймас сиңа күзләрем.

Синең белән шундый рәхәт миңа,
Назларыңда эреп югалам.
Очып йөрим күкләр киңлегендә,
Сөю бакчасына юл алам.

Синең белән шундый рәхәт миңа,
Рәхмәт укыйм һәрчак язмышка.
Үпкәләтмә бер дә, газаплама,
Рәнҗетмә син мине ялгыш та.

*Нәфисә БАЯЗИТОВА*

### Үзем кабынырмын

Вәгъдә итмә миңа алтын тавы,
«Айны бирәм!» – диеп, алдама.
Синең сөюеңне көткән чакта,
Сизми калып, зинһар, соңлама.

«Күктән йолдыз чүпләп бирәм»,
– димә.
Алар күктә тиеш янарга.
Кичләремдә, иркәм, янымда бул,
Икәү чыгыйк йолдыз санарга.

Алдамыйча тик бер җылы сүз әйт,
Җан эресен назлы караштан.
Чын күңелең белән ярат мине,
Ай балкысын синең тарафтан.

Ялкынланып, ярсып ярат кына,
Шул очкынның берсе тиюгә.
Йолдыз булып үзем кабынырмын,
Җавап итеп синең сөюгә.

*Фәнүзә САБИРОВА*

### Табигатьнең чәчкә чагы

Миләшләре – шау чәчәктә,
Алмагачлар – ак күбәк.
Язы ел да килә – моңысы
Иң-иң матуры кебек.
Төсе үзгә, исе бүтән
Әллә соңлап килгәнгә.
Берән-сәрән бөре шыткан
Корып барган имәндә.
Үземнең дә чәчкә чаклар
Язлар белән бәйләнгән.
Тик кай ара чәчкәләрем
Җимешләргә әйләнгән?
Миләшләрнең кыраудан
соң
Шикәрләнгән мәлләрен
Тансыклаган чагым, сезгә
Таныш микән хәлләрем?
Табигатьнең чәчкә чагы,
Һәр чәчкәнең үз төсе.
Яз килгәнен сизеп шыткан
Чүлмәктә алма төше.

*Елизавета МАЛОВА*

### Кемем дип дәшим икән?

Кемем дисәм, ошый төшәр,
Хуш килер күңеленә?
Ничек уйлап табаргадыр
Шул сүзне бүген генә?

Күп булса да күз кысканнар,
Сөймәдем күргән берен.
Мин – синеке, син – минеке,
Бул бары бердәнберем.

Ни дисәм дә, аз булыр кук,
Сүзләрдәмени хикмәт...
Син, гүя тәсләр балкышы,
Куясым килми чикләп.

Сусаганда – сусыл җимеш,
Син татып туймас балсың,
Һич теләмим үзгәрүен,
Ничек бар, шулай калсын.

Кемем дисәм, ошар икән,
Кемем дип, сиңа дәшим?
34 ел янәшәндә
Җылыңны тоеп яшим.

*Рифкать ИМАЕВ*



Котлыйбыз!

Хезмәт юлын типография эшенә багышлаган хезмәттәшебез – **ГӘРӘЕВА Фәнүзә Кашфелгаян кызын** юбилее белән котлыйбыз. Алга таба да гомерең күңел тынычлыгы белән сәламәтлектә, тигезлектә-муллыкта, балалар-оныклар шатлыгында уздырырга язсын.


*Ихтирам белән,*
*«Хезмәттәш авазы» коллективы*

Бик озак еллар СК заводының 1534нче цехында эшләүче кадерле кешебез – **АБДУЛВӘЛИЕВ Илсуар Галиулла улын** 60 яшь тулган истәлекле көне белән тәбрик итәбез. Үз хезмәтен яратып башкарганга, ул коллективта хөрмәтле кеше. Әгаиләдә балаларга үрнәк әти, яхшы ир. Алдагы тормышыбыз да тыныч, түгәрәк булсын, сәламәтлектән аермыйча, бер-беребезнең кадерен белеп, балалар-оныклар хөрмәтендә яшәргә насыйп итсен.

*Хатыны Рәмзия һәм балалары*

ИГЪТИБАР!
Хокук бозу, законсызлык, урлау һәм коррупция фактлары, шулай ук «ТАИФ» компанияләре төркеме өчен файдалы конструктив тәкъдимнәр һәм инновацион фикерләр турында корпоратив ышаныч телефонына хәбәр итегез.
«ТАИФ» компанияләре төркеменең корпоратив ышаныч телефоны:
8 800 333 10 09


Сезнең телефонның номеры ачыкланмый. Шалтырату бушлай.

Гинекология
УЗИ малого таза, УЗИ по беременности, лазерное лечение шейки матки без боли и операции

clinic ALPHA
Тел. 8(8555) 48-90-19
Адрес: пр. Мира, 58 (рядом с АСКО)
реклама

НИЖНЕКАМСКИЕ ШКАФЫ-КУПЕ
Звоните: 48-44-88, 8-917-884-9521

Праздничные скидки*
Милые дамы! Поздравляем Вас с замечательным праздником весны - 8 Марта!
* Сроки проведения акции: 01.03.16-20.03.16 г.
реклама

| 4 март | 5 март | 6 март | 7 март | 8 март | 9 март | 10 март |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 0° | 0° | 0° | +1° | +1° | 0° | 0° |
| +1° | +1° | +1° | +2° | +1° | +2° | +3° |

НЕФТЕХИМ МЕДИА
Хезмәттәш авазы
Газета Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ТУ16-01394нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Газетаны гамәлгә куючы: җаваплылыгы чикләнгән «Нефтехим Медиа» җәмгыяте
423574, Түбән Кама шәһәре, «Нижнекамскнефтехим» ААҖ
Мөхәррир Р.И. ЗАКИРОВ.
Телефон: 37-55-67. Электрон адрес: tatgazeta-xa@yandex.ru

Басарга кул кую график буенча 17 сәгатьтә. Бу санга 17 сәгатьтә кул куелды. Газета һәр пәнҗешәмбе чыга. Бәясе ирекле.
Тираж 3128. Индекс 00060
Газета әзер оригинал-макеттан җаваплылыгы чикләнгән «ПРИНТ СЕРВИС» җәмгыятендә басылды. 420095 Казан шәһәре, Восстание урамы, 100, оф. 174. Заказ № 245/10

Редакция адресы: 423574, Түбән Кама шәһәре, «Нижнекамскнефтехим» ААҖ, территориясе, «Хезмәттәш авазы» газетасы редакциясе